**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел/факс.: 3-13-44, 3-15-05.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/факс.: 3-13-44, 3-15-05.

КАРАР
от 20.09.2018г.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПГ-32

Актаныш муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләре) төзү турында” 2017 елның 15сентябрендәге ПГ-35номерлы карарына төзәтмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәгә төзәтмәләр кертү турында” 2015 елның14 ноябрендәге 31номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, “Гражданнар оборонасы турында” 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы эшен оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы, Актаныш муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итү һәм оештыру максатларында

карар:

1. Актаныш муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү турында” 2017 елның 15 сентябрендәге ПГ-35номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1) 1кушымтаның 2.4 пунктындагы өченче абзацны түбәндәгечә укырга: “хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге низаглар аркасында килеп чыккан табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халык арасында санитария-гигиена, эпидемиягә каршы чаралар үткәрү”;

2) 3кушымтаның 7 пунктындагы беренче абзацтагы “сыену урыны һәм шәхси саклану чаралары” сүзләрен “шәхси һәм коллектив саклану чаралары” сүзләре белән алмаштырырга”;
3) 3 кушымтаның 8 пунктындагы өченче абзацны түбәндгечә укырга: “Гражданнар оборонасы буенча билгелеләнгән тәртиптә категорияләргә кертелгән оешмалар һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмалар тарафыннан ут яктысын күрсәтмәү һәм башка төр маскировканың башка төрләре буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасын билгеләү буенча даими әзерлек хәлендә файдаланырга тиеш”;
4) 3кушымтаның 10 пунктындагы беренче абзацны түбәндгечә укырга: “10. Гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып, хәрби конфликтлар вакытында яки шул низаглар аркасында зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген беренчел тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында:”;
5) 3 кушымтаның 9 пунктындагы беренче абзацында “авария-коткару хезмәте” сүзләренә “ һәм башка кичектергесез” сүзләрен өстәргә;
6) 3кушымтаның 17 пунктындагы беренче абзацын түбәндгечә укырга: “17. “Хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге низаглар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калу өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итүгә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып тора:”.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-коммуникатив челтәрендәТатарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Башлыгы
вазифаларын башкаручы

И.Ш.Бариев